ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21 05 2024 г. № 520

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясе әйләнешен дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2023 елның 3 мартындагы 168 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 2 өлешенең 10 пунктчасына таянып, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 75 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясе әйләнешен дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларын гамәлгә ашыру чаралары турында» Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 3 мартындагы 168 номерлы карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның өченче текст өлешендәге өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балалар, мәгариф учреждениеләреннән һәм спорт объектларыннан ваклап сату һәм җәмәгать туклануы предприятиеләренә керүгә кадәр араны исәпләү социаль объектның иң якын чик ноктасыннан (аерым территория булган очракта - аерым территориядән) сәүдә объектының иң якын чик ноктасына кадәр туры сызык буенча башкарыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.И. Мөхәммәтьяновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов